**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станция Высокая Гора,
Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЕ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Кооперативная ур., 5, Биектау т/ю станциясе поселогы,
Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-50, факс: 2-30-86, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**
**от 05.09.2022** **№ 863**

## 16:16:080301:26 кадастр номерлы җир кишәрлеге территориясен межалау проектын раслау турында

Россия Федерациясе Җир кодексы, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, 2022 елның 31 августындагы Биектау муниципаль районы территориясендә җирдән файдалану һәм төзелеш комиссиясе бәяләмәсе нигезендә, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. «Баньян» ҖЧҖ милкендәге Татарстан Республикасы, Биектау муниципаль районы, Биектау авыл җирлеге, Мелиораторлар ур., 24 ж/к адресы буенча урнашкан, 16:16:080301:26 кадастр номерлы булган җир кишәрлеге (җирләр категориясе - торак пунктлар җирләре, рөхсәт ителгән файдалану төре - Җитештерү урынын урнаштыру өчен) территориясен межалау проектын расларга.
2. Әлеге карарны Интернет челтәрендә Биектау муниципаль районының рәсми сайтында: http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ веб-адрес буенча һәм «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда: http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштырырга.
3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә дип билгеләргә.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны район башкарма комитетының төзелеш, архитектура һәм ТКХ бүлеге башлыгы А.М. Хөснетдиновка йөкләргә.

Биектау муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе
вазыйфаларын башкаручы Д.Ф. Шәйдуллин